**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2020елның 14 декабрендәге** **27-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 декабрендәге 61-РС номерлы карары белән расланган, 2019елның 11 декабрендәге 96-РСномерлы карары үзгәрешләре белән «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең уңай яшәү шартларына, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында Лаеш муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә;

2. Гавами тыңлаулар уздыру чорын кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр аларны уздыру турында хәбәр итү мизгеленнән алып дип билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы кимендә бер һәм өч айдан да ким була алмый;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетына:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган иҗтимагый фикер алышуларның башлануы турында хәбәр әзерләргә;

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 14 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртип нигезендә әлеге Карарның 3.1 п. күрсәтелгән хәбәрне бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.3. Әлеге Карарның 2 п. күрсәтелгән чорда гавами тыңлаулар уздырырга;

3.4. Халык тыңлаулары тәмамланганнан соң 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар

нәтиҗәләре турында бәяләмәне ахыргы карарны кабул итү өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә..

4. Әлеге карарны « Кама ягы » (Камская новь) район газетасында, Интернет мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык- муниципаль район Советы рәисе И.Ф.Зарипов**